**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
КАРАРЫ**

13 ноябрь, 2025 ел. № 6

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 08 ноябрендәге 41/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 26 ноябрь көнне 2025 елның сәгать 18.00 Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылында Березовая, Садовая, Зеленая, Тополиный тыкрыгы, Центральная урамнарында, Челнинская, Тукай к-с, Жукова к-с, Ленин, Школьная, Овражная, Весенняя, Новая, Новоселов, Молодежная, Солнечная салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 26 ноябрь көнне 2025 елның сәгать 19.00 Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылында Придорожная, Луговая, Цветочная, Полевая, Сармановкая, Юбилейная, Автозаводская, Космонавтов, Энергетиков, Монтажная, Береговая, Ботаническая, Радужная, Тихая, Уютная, Ближняя, восьмого Марта, Дачная, Загородная, Июньская, Казанская, Летняя, Магистральная, Малая, Студенческая, Степная, Физкультурная, Сельская урамнарында, Беренче квартал юл, Икенче квартал юл урамнарында, үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык җыенын уздыру өчен Новотроицк авыл яшәүчеләрнең исемлеге аерым бүленә, сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы

студентларга, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә әлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Новотроицк авылында вак таш сатып алу);

- урам яктырту эшләрен башкару (электроматериаллар сатып алу, Новотроицк авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Новотроицк авылында мафлар урнаштыру).»

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Гражданнар җыеннарын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицкое авыл җирлеге, Новотроицкое авылы, Ленин ур., 11 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

6. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева